## Г.Ибраһимовның “Яшь йөрәкләр” романы һәм гыйльми, әдәби-тәнкыйди фикер

XX гасыр башында әдәби әсәрләренең сәнгатьчә матурлыгы, идея эчтәлегенең иҗтимагый-фәлсәфи яңгырашы, сүз-сурәт, тасвирый чара – алымнарның муллыгы, лирик хисси-эмоциональ кичерешләрнең тирәнлеге белән аерылып торган Г.Ибраһимов үз иҗатында төрки-татар, шәркый традицияләрне гареб-рус мәдәнияте, әдәби-фәлсәфи фикере ирешкән казанышлар белән баетуның уңышлы һәм нәтиҗәле үрнәген күрсәтә. Дөнья әдәбиятының алтын фондын баеткан “Яшь йөрәкләр” романы шушы юнәлештә иҗат ителгән әсәрләрнең берсе булып тора.

Роман әдәби-тәнкыйди һәм гыйльми-нәзари фикер тарафыннан хуплап каршы алынып, әдәби җәмәгатьчелектә зур кызыксыну уята. Күләмнәре, бәя-хөкемнәре, фикер тирәнлекләре, бәяләү куәсе төрле дәрәҗәдә булган дистәләгән язмалар дөнья күрә. Бу фактка шул елларда ук игътибар ителә: “Инде калды “Яшь йөрәкләр” [...] эчендә халык күңелен тибрәтерлек хасияте булгач, укучы аны салкын гына, тавышсыз гына узгара алмады. Әсәр телгә алынырлык булгач, аның хакында тәнкыйть булсын, тәкърыйз булсын байтак кына язылды, күп яхшы каләм ияләре мөхәрриренең үткәне, киләчәкләре хакларында күп фикерләр сөйләделәр һәм Галимҗан әфәнденең киләчәгенә зур гына өметләр багланды” [2:189-192]. Алар бер-берсеннән жанр, шәкел төрлелеге белән дә аерылып торалар.

Х.Кәримов 1913 елда “Аң” журналының 18 санында басылган программ характердагы “Әдәбиятта үзгәреш кәтелә” дигән монографик мәкаләсендә Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимовларның 1910 еллар иҗатына, ә соңгысының “Яшь йөрәкләр” романына таянып, милли әдәбиятның идея эчтәлеге һәм сәнгатьчә эшләнеше ягыннан яңарышы, сыйфади үзгәрешләр кичерүе хакында нәтиҗә ясый: “Татар теләге дә акрынлап-акрынлап әдәбиятта Гаязныкыннан башка да тәмле азыклар табыла башлады һәм азрак элеккегедән үзгәлек, бер татлылык сизелгән мөхәррирләрнең әсәрләрен мактый башлаудан да тартынмады, әүвәлге мәшһүр, кадерле мөхәррире Гаязның мөкәммәл падишаһлык сөргән вакытларында ук Тукаев, Әмирханов һәм Ибраһимов кеби [...] Гаязга шәкерт затларны замана мөхәррирләре, шул минутларда аның җаны теләгән нәрсәләрне язучы яшь вә өмидле мөхәррирләр дип игълан итте” [2:189-192]

Уйгур “Яшь йөрәкләр” (1913) рецензиясендә сөйләшүне татар әдәбиятында роман жанрының торышы турындагы бәя-хөкемнәреннән, уйланулардан башлый. Мәгълүм булганча, Уйгур тәхәллүсе белән XX гасыр башында матбугат битләрендә Фуад Туктаров языша. Моңа кадәр жанр сыйфатлары белән һич кенә романга җавап бирмәгән әсәрләргә “милли роман” дип куелып, терминның бары тик утилитар максатларда кулланылышын билгели. Алга таба автор бу эпик төрнең үзенчәлекләре хакында фикер йөртеп, милли әдәбиятта Г.Исхакый, Ф.Әмирханнардан роман өмет ителсә дә, яза башлаган әсәрләренең тәмамланмый калуы сәбәпле, татар укучысының хыяллары тормышка ашмавын белдерә. Уйгур Г.Ибраһимовның “Яшь

йөрәкләр”ен рус әдипләре Н.В.Гоголь, И.А.Гончаров, М.Ф.Достоевскийларның атаклы әсәрләре белән янәшә куеп, татар дөньясында чын мәгънәсендә роман язылуын ассызыклый һәм аның милли әдәбиятны жанр ягыннан төрләндерүе хакында нәтиҗә ясый. Роман XX йөз башында әдәби әсәрне бәяләүнең төп бизмәненә әверелгән миллилек ноктасыннан югары куела: “Романның сюжеты үз тормышыбыздан алынган; шәхесләр, күренешләр, әсбап вә җиһаз һәммәсе татарныкы; шунлыктан бу – хакыкый бер милли роман” (3). Автор тарафыннан романның сюжеты нигезендә яткан төп конфликт аталар һәм балалар тартышы рәвешендә гәүдәләнгән искелек белән яңалыкның каршылыгы төсендә күрсәтелә. “Яшь йөрәкләр” романына язылган рецензияләрдә, гәрчә хәзерге әдәбият белемендә тәнкыйди реализм агымының поэтикасына нисбәт ителсә дә, тип термины фәнни әйләнештә йөри. Чор гыйльми-нәзари фикерендә ул характер төшенчәсенә синоним рәвешендә файдаланыла. Уйгур да, шулай ук үзенең нәзари уйлануларын дөнья әдәби-эстетик, фәлсәфи фикере ирешкән биеклектә һәм әдәби бәйләнышлар яссылыгында оештырып, татар гыйльми фикерен Аурупа киңлекләренә алып чыккан Г.Гобәйдуллин да әсәр хакында типлар аша хөкем йөртәләр.

Г.Гобәйдуллинның “Яшь әдәбиятыбызда яшь йөрәкләр” дигән хезмәте саф әдәби тәнкыйть жанры кысаларында язылган. Ул романның “халык музыкасына артык әһәмият бирү”, “сөюгә әллә нинди зур хыялый, әфләтүни бер мәгънә бирү”, “каһарманнарның үзләре яшәгән тирәлек белән кискен каршылыгы” кебек төп идея-эстетик үзенчәлекләренә таянып, беренчеләрдән булып, Г.Ибраһимовның “Яшь йөрәкләр” романы мисалында 1910 еллар татар әдәбиятында яңа иҗат юнәлеше калыплашуы хакында нәтиҗә ясый: “Мин хәзерге реалист булып газаплануны үзен ялган реализм дияр идем. Чөнки хәзер безнең милли хисебез куәтләнгән, милли музыка, халык җыры вә музыкасына әһәмият биргән, үзебезнең үткән көннәребезне артыбызга борылып карый башлаган бер заманыбыз, бездә ник романтизм булмасын” [4:189-192]. Рецензия авторы милли әдәби-гыйльми фикернең яңа тип романтизмны үзләштерүен, аның әһәмиятен “тарихи бер вакыйга” буларак бәяли.

Алга таба Г.Гобәйдуллин романда характер дәрәҗәсенә җиткерелеп гәүдәләнеш алган геройларны, һәрберсенең индивидуаль үзенчәлекләрен бәяләүгә күчә. Зыя, Сабир, Мәрьям, Җәләлетдин муллалар әсәрнең төп каһарманнары төсендә бәяләнәләр. Галимнең Зыя, Сабир турындагы бәя-хөкемнәре үзләренең теоретик тирәнлеге, югарылыгы, өр-яңалыгы белән аерылып торалар. Зыя образы милли чынбарлык белән бәйләнештә каралып, татар әдәбиятында тәүге тапкыр тудырылган яңа образ буларак бәяләнә. Г.Гобәйдуллин Сабирны характер итеп формалаштырган һәм башкалардан аерып куйган төп сыйфатын зур осталык, әдәби сизгерлеклек белән тотып ала һәм Зыяга контрастта, капма-каршы куеп күрсәтә: “Агасы Сабир Зыяның бөтенләй киресе. Ул чын Руссо фикерендә, эш өчен, чын кул эше өчен туган бер кеше. Ул мәдәниятне яратмый, шәһәрне сөйми, аңар хәтта язу тану да мөһим түгел, ул шундый кызны хатынлыкка да ала. Ул җитди кеше, ул авыр, сабыр, гакыллы уйчан, “мөхакәмәнең салкын колы”. Зыя хис белән яшәсә, Сабир гакылы белән яшидер” [4:189-192]. Әдип стиленең матурлыгы, үз

каһарманнарының психологиясен ачуда, күңел төпкелләрен сурәтләүдәге осталыгы шартлы-романтик стильдә ассызыклана: “Ибраһимовның бу әсәрендәге тасвирлар эчендә иң муаффәкыятьле чыкканы бәгъзе урыннарда рухның дулкынын, аның буранын яисә ялтыравыклы күл өсте кеби тын булган заманын күрсәтә торганыдыр” [4:189-192]. Авторның күләмле рецензиясендә алга таба әдип иҗатына мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан үстереләчәк, тирәнәйтеләчәк тенденцияләр, “Яшь йөрәкләр” романын гыйльми-тәнкыйди шәрехләүнең методологиясе, фәнни концепциясе бирелә.

1917 елгы Октябрь борылышына кадәр үк язылган мәкаләләрендә матур әдәбиятның социологиясе белән артык мавыгып, аерым әдәби мәсьәләләрне аңлауда берьяклылык күрсәткән Ф.Сәйфи-Казанлы “Яшь йөрәкләр” романының темасын, төп мативларын, үзәк конфликтын дөрес билгеләсә дә, Г.Ибраһимовны үз каһарманнарны характер буларак ачарлык, калыплаштырырлык шартларга куймауда, вакыйгалар эчендә күрсәтмәүдә кискен гаепләп чыга: “Бу ике төрле көрәшне мөхәррир күрсәтә алган, ләкин мөхәрриргә әллә никадәр хөсне зан (яхшы фикере – Г.Т.) булса да бу көрәшү, бу тартышулары күрсәтер өчен сайлаган зәминнәренең, әсаслы (нигезле – Г.Т.) итеп, халәте руханияләрен (рухи халәтләрен – Г.Т.) һәм тормышларын мөхәррир үтәли күреп язмаган төсле.Бөтен күрсәтелгән типлар арасыннан бер генә булсын тәмам бетерелгән, түгәрәкләнгән, тормышта тотып күрсәтерлек бер тип та юк дисәң дә гөнаһ булмас” [8:49-54]. Безнең карашыбызча, автор романтик әсәрнең тормыш белән бәйләнешен артык гадиләштереп аңлый, матур әдәбият белән реаль чынбарлык арасында тигезлек билгесе үткәрә. Мәгълүм булганча, Г.Ибраһимов әдәбият-сәнгать хакындагы уйланулары белән 1910 еллар татар гыйльми-нәзари фикерендә бер юнәлеш, мәктәп тудыра. Ф.Сәйфи-Казанлы әдип иҗат концепциясенең нигезен тәшкил иткән нәфис әдәбият матурлыкны гәүдәләндерергә тиеш, “сәнгать әсәре булу өчен тормышны күрсәтү генә җитми, шул тормышның рухын, җанын ачарга кирәк” [1:31] дигән кагыйдәләренә каршы чыга. Мәкалә авторы, башкалар тарафыннан төп геройлар буларак танылып, романда зур урын тоткан, яңа тип төсендә бәяләнгән Зыя, Мәрьямгә тискәре карашын ташлый.

Әдәби-тәнкыйди фикер “Яшь йөрәкләр” романының тышкы төзелешендәге, корылышындагы кимчелекләргә дә үз игътибарын юнәлтә. Әдәби әсәрдә сурәтләнгән вакыйгалар арасындагы бәйләнешләрнең зәгыйфьлеге, таркаулык, аерым сюжет җепләренең югалуы, Зыя, Мәрьямнәрнең үз характер сыйфатлары белән сәбәпле бәйләнештә аңлатып булмый торган адымнар ясавы, я булмаса лирик чигенеш, фәлсәфи катламнар белән язучының артык мавыгып китүе романның җитешсезлекләре төсендә күрсәтелә.

Совет хакимияте урнашкач, яңа иҗтимагый-сәяси вәзгыятьтә әдәбият-сәнгатькә караш тамырдан үзгәрә. Милләткә хезмәт итү идеясе үзгәртелеп, сүз сәнгатенең иҗтимагый вазифасы социализм төзелешенә хезмәт итүдә билгеләнә. Яшәеш һәм милли чынбарлыкның актуаль мәсьәләләрен гәүдәләндерү кире кагылып, Сталинның “социализм җиңә барган саен, сыйнфый көрәш көчәя бара” дигән формуласы нигезен тәшкил иткән сыйнфый көрәш проблемасын күтәрү матур әдәбияттан таләп ителә башлый. Менә

шушындый катлаулы шартларда әдәбият белемендә көн тәртибенә куелган әдәби мирас мәсьәләсенә нисбәтле, Г.Ибраһимовның беренче чор иҗатын шәрехләү, моңа кадәрге бәя-хөкемнәрне яңарту башлана.

1926 елда Г.Сәгъдинең XX гасыр башы татар әдәбияты тарихын иҗтимагый-милли, мәдәни яңарыш хәрәкәте белән тыгыз бәйләнешкә яктырткан "Татар әдәбияты тарихы" хезмәте языла. Анда Г.Ибраһимовка монографик бүлек багышланган. Галим әдипнең иҗатында зур урын тоткан "Яшь йөрәкләр" романына туктала. Бу өлешнең бүген көн әдәбият фәне өчен әһәмияте "Яшь йөрәкләр"не яңача шәрехләүдә, аны өйрәнүгә яңа сызыклар өстәүдә түгел, ә романга язылган рецензияләрдәге, мәкаләләрдәге фикерләрне барлап, җыеп системага салуда билгеләнә һәм шул ягы белән кызыклы. Дөрес, автор чор идеологиясе басымы астында, әдипнең бөтен төр әсәрләрен җыйнап, тикшереп, ике төп хосусиятнең: көрәш һәм хезмәтнең кызыл җеп булып сузылып баруын күрсәтә. Әмма ул нәтиҗә галимнең романны анализлавына, аңа кадәр әйтелгән бәя-хөкемнәргә мөнәсәбәт белдерүенә зыян салмаган, ә декларатив төстә генә калган. "Әсәр татардагы романтизм дулкыннары астында калып, шуның тәэсире белән язылуга карамастан, мәүзугының яңалыгы, мөндәриҗәсенең киңлеге, алган каһарманнары, тел-өслүбенең яңа һәм үткенлеге белән башкалардан, шөбһәсез, аерым урын тота иде" [7:254]. Алга таба галим тарафыннан яңа татар прозасының хосусиятләреннән фәлсәфилек, психологизм калкытып куела һәм ул сыйфат әдипнең индивидуаль стиль үзенчәлеге, каләменең көче, таланты төсендә бәяләнә. "... монда вакыйга һәм нәрсәләр турындагы фәлсәфи карашлар, эчке рухи дулкыннар (бигрәк тә романтизм дулкыннары) яхшы ук киң бер алым белән бик оста тасвир ителде. Романда күренгән бу хосусияттә татар матур әдәбиятында үзенең тулылыгы белән беренче мәртәбә күренгән бер хәл иде. Әдип бу романы белән үзен чыннан да эчке дулкыннарны тасвирда да көчле әдип икәнен күрсәтте." [7:255]

1927 елда әдәби җәмәгатьчелек Г.Ибраһимовның 20 еллык әдәби-гыйльми, иҗтимагый хезмәте бәйрәмен билгеләп үтә. Шушы уңайдан әдипнең күпкырлы эшчәнлеген өйрәнү активлашып китә. Г.Нигъмәти, Г.Сәгъди, Җ.Вәлиди, Г.Гали һ.б.лар күләмле мәкаләләр белән матбугат битләрендә чыгыш ясыйлар. Бу язмалар яңадан бергә тупланып "Галимҗан Ибраһимов" дигән исем белән 1928 елда аерым җыентык булып басылып чыга.

1920 елларның ахырында – 1930 елларның беренче яртысында язылган Г.Нигъмәти үзенең күләмле монографик мәкаләләрен Г.Ибраһимовның әдәби эшчәнлеген өйрәнүгә багышлый. Галим Г.Ибраһимовның әдәби әсәрен, шул исәптән "Яшь йөрәкләр" романын да Көнбатыш-рус әдәбияты, мәдәнияте ирешкән казанышлар ноктасыннан торып, мәдәни-тарихи мәктәп кагыйдәләренә, принципларына нигезләнеп шәрехли, ягъни дөнья әдәбияты контекстында карый. "Г.Ибраһимов һәм аның әдәби иҗат юлы" (1932) дигән монографик мәкаләдә "Яшь йөрәкләр" романы ике яссылыкта: образлар системасы һәм композиция, тел, стиль үзенчәлекләре яссылыгында анализлана. Бу урында шуны да искәртергә кирәк: чорның катлаулы булуына карамастан, галимнең бу мәкаләсендәге әдәби-эстетик карашлары идеологиядән, сәясәттән азат. Ә.Галиева Г.Нигъмәтинең әсәрдәге образлар системасын өйрәнүдәге

яңалыгын, индивидуаль сыйфатын билгеләп болай дип билгели: “Ул, беренчедән булып, “Яшь йөрәкләр” романында әдәби образларның романтик гомумиләштерү алымы белән эшләнүен, алардагы индивидуаль, шәхси сыйфатларның романтик типлаштырылып, гомумиләштерелеп, үстерелеп, көчәйтелеп бирелүен күрсәтте” [2:194]. Нигъмәти тарафыннан әсәрнең тел-стиль үзенчәлекләре дә, композиция элементлары да әдипнең романтик хикәяләү стиленә буйсындырылуы хакында нәтиҗә ясала. Хезмәт авторы романның әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан теләктәшлек табу гына түгел, ә аның тәэсирендә әдәби әсәрләр иҗат ителүен, ягъни Г.Ибраһимовның әдәби мәктәп тудыруын әйтеп чыга: “Теләктәшлек табу белән генә калмады, “Яшь йөрәкләр” сугарылган уй, тойгылар белән язылган әсәрләр башкалар каләме белән дә чыгарыла киләләр иде. Бу соңгыларга мисал итеп 1913-1916 нчы еллар да “Аң” битләрендә басылган күп кенә әдип, шагыйрьләрне алырга була” (9, 91 б.). Ул “Яшь йөрәкләр” романында зур урын бирелгән тәкъдир, язмыш, яшәү, үлем, гомер чиклелеге кебек мәсьәләләрне яктырткан фәлсәфи хикәяләрне дә күз алдында тотып шушы фикергә килә.

Менә шундый төпле, тирән тикшеренүләргә, кызганычка каршы, 1930 елларның уртасында чик куела. Мәгълүм булганча, Г.Ибраһимовның баш өстендә болытлар куера башлый. Ул, нахакка гаепләнеп, 1937 елда Ялтада дәваланып яткан җирендә кулга алына. Нәтиҗәдә әдипкә “халык дошманы” дигән мөһер сугылып, аның исеме һәм рухи мирасы ике дистә елга матур әдәбияттан, халык күңеленнән бөтенләй сызып ташлана. И.В.Сталин вафат булып, шәхес культы игълан ителгәч, тарихи дөреслек торгызылып, әдипнең исеме, рухи мирасы үз халкына, милләтенә кире кайтарыла һәм 1956 елда ук Г.Ибраһимовның ике томда сайланма әсәрләре дөнья күрә. Аңа кереш мәкаләне Г.Халит яза. Галимнең “Яшь йөрәкләр” романына, гомумән әдипнең романтик хикәяләренә карашлары шактый каршылыклы. Әдәби әсәргә гомуми уңай мөнәсәбәт саклаган хәлдә, ул романның иҗат методына, эчтәлегенә чор идеологиясе тәэсирендә берьяклы якын килә: “Ләкин Ибраһимов иҗатында көчәйгән романтизм настроениеләре вакыты-вакыты белән декадентлык әдәбиятындагы мотивларга бик тә якын килделәр һәм аңардагы реалистик яралгыларны сүндерү куркынычын тудырдылар. Шуның бер чагылышы буларак, “мәхәббәт һәм сәнгать культы” кабарынкы төс алды. “Сөю-сәгадәт” (1911) һәм “Яшь йөрәкләр” (1912) кебек әсәрләрдә шәхеснең төп идеалы, рухи теләге – мәхәббәт һәм сәнгать дигән караш алга этәрелде” (10, 12 б.). Әлбәттә, Г.Халитнең карашларында чор каршылыгы, романтизмга шикле карашның каршылыгы ята. Шушы еллардагы аерым мәкаләләрдә күзәтелгән әдип иҗатын көчләп реализм кысаларына кертеп утыртырга тырышу тенденциясе дә шуның чагылышы булып тора.

Г.Ибраһимовның күпкырлы эшчәнлеген өйрәнүнең киңәюе, фәнни-гыйльми яктан тирәнәюе 1960-1980 елларга туры килә. Н.С.Хрущев исеме белән “җепшеклек” чоры, совет әдәбият белемендә уңай үзгәрешләр, аеруча иҗат юнәлешләреннән романтизмның реабилитацияләнүе, ягъни танылуы һәм кабул ителүе, татар гыйльми фикеренең көче, егәрлеге үсү, әдипнең тууына 90, 100 ел тулу уңаеннан үткәрелгән фәнни-гамәли конференцияләр Г.Ибраһимов

рухи мирасын гыйльми күзаллауның офыкларын киңәйтүгә җирлек әзерлиләр. Шул исәптән “Яшь йөрәкләр” романының идея-эстетик үзенчәлекләрен яңача шәрехләүгә юллар ачыла.

Әдип тормыш юлын һәм иҗатын монографик планда гыйльми-күзаллауга яңа сулыш әдәбият галиме М.Хәсәнов эшчәнлегендә ясала. Галимнең “Галимҗан Ибраһимов” (Казан, 1964), “Галимджан Ибрагимов” (Казань, 1977), “Писатель, ученый, революционер” (М., 1987) һәм күпсанлы мәкаләләрендә әдипнең рухи мирасы яңа яшәеш ала, аны аңлау теоретик планда тирәнәя. М.Хәсәновның эзләнүләрендә романның идея эчтәлеге, сәнгатьчә эшләнеше, матурлыгы, образлыгы хакындагы бәя-хөкемнәр тирәнәйтелә: “Яшь йөрәкләр” – үзенең жанры ягыннан социаль-психологик роман. Анда иҗтимагый әһәмиятле социаль проблема геройларның тирән психологик кичерешләре аркылы сурәтләнә. Ибраһимов татар әдәбиятында социаль психологик роман жанрын беренче башлап урнаштыручылардан иде” (11, 41 б.). Хезмәт авторы образлар иҗат итүдә әдипнең күптөрле яңа алымнарга, тасвирый чараларның бай арсеналына мөрәҗәгать итүен дәлилли һәм аларның традицияләрен барлау, яки әдәби багланышлар, әдәби йогынты яссылыгында бәяләү, рус әдәбияты белән чагыштырма, типологик планда өйрәнүе белән “Яшь йөрәкләр”не өйрәнү тарихын яңа штрихлар, тенденцияләр белән баета. Дөрес, М.Хәсәновның да әдәби карашлары шул чорда хакимлек иткән идеология, ориентир йогынтысы белән аңлатыла торган берьяклы мавыгулардан азат түгел. Мәсәлән, ул әдип романтизмы турында сүз алып барганда “революцион”, “прогрессив” романтизм терминына мөрәҗәгать итә. Әдип каләменең реализмга күчеш ясавының катгыйлыгын раслап болай дип яза: “Яшь йөрәкләр” – Г.Ибраһимовның романтизм дәверен кичереп, реалистик иҗат принципларына күчә баруын күрсәткән әсәр” (11, 40 б.).

Р.Ганиеваның язучының әдәби эшчәнлегенә нисбәтле фәнни эзләнүләрендә бу әдәби әсәрне аңлау һәм үзләштерүдә яңа сызык барлыкка килә. Галимә “Яшь йөрәкләр” романын әдәби багланышлар яссылыгында өйрәнүне тагын да киңәйтеп, әсәрдә шәркый традицияләрнең дә гәүдәләнешен әйтеп чыга. Гыйльми-тәнкыйди язмаларында XX йөз башы татар әдәбиятын Көнчыгыш һәм Көнбатыш әдәбиятларының казанышлары белән баетуны яклаган Г.Ибраһимовның үз карашларын каләме белән раславы “Яшь йөрәкләр” мисалында дәлилләнә. “Көнчыгыш Ренессансының бөек галимнәре, философлары, шагыйрьләре иҗатына, гуманистик эчтәлекле халык әдәбиятына Галимҗан Ибраһимов һәр вакытта да зур ихтирам белән карый, аның кайбер алымнарын үзенең әсәрләрендә файдалана” (12, 135 б.). Әсәргә төрек мәгърифәтче әдипләреннән Нәмыйк Кәмал, Әхмәд Рәсим; реалистик төрек әдәбиятын нигезләүчеләрдән Халид Зыя Ушаклыгөл, төрек романтик шагыйре Габделхак Хәмид иҗатларының тәэсирләре билгеләнә.

Көнчыгыш әдәбиятларында жанр буларак яшәгән төш алымын отышлы файдалану, әсәрнең корылышы белән бәйле булган хикәя эчендә хикәя композицион чарасы, аерым каһарманнар бирелеше, аеруча Мәрьямнең тышкы һәм эчке дөньясын бирүдә охшашлык, төрек мәхәббәт романнарыннан алынган реминисценцияләр, әсәр тукымасына, сюжетына уңышлы кертеп җибәрелгән

маҗаралы, гыйбрәтле вакыйгалар “Яшь йөрәкләр” романының Шәрык әдәбияты, мәдәнияте белән бәйләнешы хакында сөйли.

Г.Ибраһимов галимә тарафыннан “яңа заман татар романтизмының нигез ташларын салучы зур әдипләрнң берсе” буларак бәяләнә. Хезмәттә “Яшь йөрәкләр” романы һәм башка әсәрләре мисалында XX йөз башында шәрык романтизмы һәм гареб романтизмы эстетикасы атрибутларын, сыйфатларын синтезлаган яңа тип романтизмы калыплашуы хакында фикер ныгытыла.

XX гасыр ахыры XXI гасыр башларында 20 йөз башы әдәби хәрәкәтенең закончалыкларын, үсеш тенденцияләрен барлау юнәлешендә әдипнең аерым әсәрләренә игътибар ителсә дә, Г.Ибраһимовның иҗатын, кызганычка каршы, монографик планда яктырткан хезмәтләр юк әле. Шулай да М.Хәсәнов, Р.Ганиева, Д.Заһидуллина хезмәтләрендә әдипнең иҗатына, аерым алганда “Яшь йөрәкләр”гә игътибар ителеп, аны өйрәнү концепциясе яңартыла бара.

Күзәтүләргә нәтиҗә ясап, шуларны әйтергә мөмкин. Г.Ибраһимовның “Яшь йөрәкләр” романын тәнкыйди бәяләү һәм тикшерүнең бергасырлык тарихы бар. XX гасыр башында ул милли чынбарлыкның иҗтимагый, мәдәни-рухи алгарышы, заман һәм мохит тәэсире белән сәбәпле бәйләнештә, гомуммилли яссылыкта тикшерелә һәм ул татар әдәбиятына сыйфат үзгәрешләре, яңарыш алып килеп, милләтнең “йөрәген, җанын һәм аның тормышка булган мөнәсәбәтен күрсәтә торган” әсәр буларак бәяләнә. Романны гыйльми күзаллауның фәнни концепциясе үз таяну нокталарын, принципларын барлый.

1917 елгы Октябрь борылышыннан соң әсәрне өйрәнү тарихы катлаулы һәм каршылыклы төс ала. Иҗтимагый-сәяси вәзгыять, кискен үзгәргән рухи-әхлакый, әдәби-мәдәни, фәлсәфи-эстетик кыйммәтләр романны гыйльми шәрехләүгә зур йогынты ясый. Г.Сәгъди, Г.Нигъмәти хезмәтләрендә аңа уңай мөнәсәбәт сакланган хәлдә, татар әдәбиятында яңа стиль җирләштерү, психологик типлар тудыру әйтелә, әсәрнең сюжетына, композицион катламнардан психологик, фәлсәфи, тел катламына игътибар ителә. Язучыга нахакка халык дошманы мөһере сугылып, ике дистә елга исеме һәм рухи мирасы максатлы рәвештә онытырылып торганнан соң, совет чорында әдип мирасын, шул исәптән “Яшь йөрәкләр”не өйрәнүнең дә икенче күтәрелеше Г.Халит, М.Хәсәнов, И.Нуруллин, Г.Ганиева һ.б.ларның эшчәнлекләре, аннан соң әдипнең тууына 90, 100 тулу уңаеннан фәнни гамәли конференцияләр дә аның рухи мирасын төрле яссылыкта тикшеренүләр белән бәйле.

**Әдәб.:**


1. Әмирхан Ф. Әсәрләр дүрт томда. 4-том. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1986. – 390 б.
2. Кәримов Х. Әдәбиятта үзгәреш көтелә // Аң. – 1913. - № 18. – 189-192 б.
3. Уйгур “Яшь йөрәкләр” // Йолдыз. – 1913. – 21 апрель.
4. Гобәйдуллин Г. Яшь әдәбиятыбызда яшь йөрәкләр // Аң. – 1913. - № 11. – 189-192 б.

5. Сәйфи-Казанлы Ф. Яшь йөрәкләр. Тәнкыйть // Хокук вә хәят. – 1913. - № 3. – 49-54 б.
6. Галимҗан Ибраһимов һәм хәзерге заман. – Казан: Фикер, 2003. – 272 б.
7. Сәгъди Г. Татар әдәбияты тарихы. Дәреслек-кулланма. – Казан: Татгосиздат, 1926. – 300 б.
8. Галиева Э. Татар әдәбияты белемендә культура-тарих мәктәбе. – Казан: Фән, 2002. – 360 б.
9. Нигъмәти Г. Сайланма әсәрләр. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1958. – 278 б.
10. Халит Г. Галимҗан Ибраһимов (Тормышы һәм иҗаты) // Сайланма әсәрләр. Ике томда. 1-том. – Казан: Таткнигосиздат, 1957. – 7-40 б.
11. Хәсәнов М. Галимҗан Ибраһимов: Тормыш һәм иҗат юлы. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1964. – 332 б.
12. Ганиева Р. Галимҗан Ибраһимов һәм Көнчыгыш әдәбиятлары // Казан утлары. – 1977. - № 3. – 134-141 б.